ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Матди булмаган этномәдәни байлыклар өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру барышы хакында

«Хөкүмәт сәгате» кысаларында Татарстан Республикасы мәдәният министры И.Х. Әюпованың «Матди булмаган этномәдәни байлыклар өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2017 елның 26 маендагы 34-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру барышы хакындагы мәгълүматын тыңлап фикер алышканнан соң, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы мәдәният министры И.Х. Әюпованың мәгълүматын игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

2.1. Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче Россия Федерациясе халыклары мәдәниятенә ярдәм итүгә, аны саклауга, үстерүгә һәм өйрәнүгә, Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче Россия Федерациясе халыкларының этномәдәни күптөрлелеген, шул исәптән матди булмаган этномәдәни байлыкларын, саклауга юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыруны дәвам итәргә.

2.2. Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның традицион мәдәниятенең республика бәйрәмнәрен («Каравон», «Сабан туе», «Семык», «Валда шинясь», «Уяв», «Гырон быдтон», «Иван Купала», «Питрау» һәм башкалар) үткәрүгә ярдәм күрсәтүне дәвам итәргә.

3. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

3.1. Татарстан Республикасының матди булмаган этномәдәни байлыклар объектлары реестрын формалаштыруны һәм алып баруны, аңа ел саен республиканың матди булмаган этномәдәни байлыкларының кимендә җиде объектын кертүне тәэмин итеп, дәвам итәргә.

3.2. Татарстан Республикасыннан кимендә ике матди булмаган этномәдәни байлыклар объектын Россия Федерациясенең федераль дәүләт

матди булмаган этномәдәни байлыклар объектлары реестрына кертү өчен заявкалар әзерләүне тәэмин итәргә.

3.3. Матди булмаган этномәдәни байлыклар объектлары турында басма җыентык чыгару мөмкинлеген карарга.

3.4. Үсеп килүче буын арасында матди булмаган этномәдәни байлыклар объектларын популярлаштыруга, саклауга һәм торгызуга юнәлдерелгән фестивальләр һәм конкурслар үткәрү мөмкинлеген карарга.

3.5. Җирле үзидарә органнары белән берлектә:

– Татарстан Республикасының һәр муниципаль районыннан һәм шәһәр округыннан кимендә ике матди булмаган этномәдәни байлыклар объектын Татарстан Республикасының матди булмаган этномәдәни байлыклар объектлары реестрына кертү өчен аларны ел саен эксперт советы тарафыннан карауны тәэмин итәргә;

– Татарстан Республикасы муниципаль районнарында һәм шәһәр округларында матди булмаган этномәдәни байлыклар турында методик семинарлар оештырырга.

3.6. Югары һәм урта һөнәри белем бирү профильле мәгариф оешмалары белән берлектә матди булмаган этномәдәни байлыклар объектларын ачыклауга, өйрәнүгә, актуальләштерүгә һәм популярлаштыруга юнәлдерелгән студент проектларына ярдәм итү мөмкинлеген табарга.

3.7. «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгы белән берлектә:

– Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы вакыйгаларын һәрьяклап яктыртуны дәвам итәргә;

– массакүләм мәгълүмат чараларында матди булмаган этномәдәни байлыклар объектларын популярлаштыруга юнәлдерелгән материалларны бастырып чыгаруга ярдәм күрсәтергә;

– матди булмаган этномәдәни байлыклар турында телевидение тапшырулары һәм радиотапшырулар циклын булдыру мөмкинлеген карарга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитетына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 14 сентябре
№ 2153-VI ДС